Бәдигъ мәзин елъязмасы

1906 елның февралендә Бәдигъ мәзиннең йортыннан чыгып китеп ата күркәсе югала. «Казан мөхбире» газетасының шул елгы 3нче февраль (№ 32) санында, игъланнар бүлегендә: «Бәдигъ мәзиннең ата күркәсе чыгып югалмыш. Китерүчегә бер сум һәдия кыйлыначак», — дигән игълан басылып чыга. Шул ук елны бу хәбәрне сатира әдәбияты мыскыллы көлке материалына әйләндерә. Оренбургта чыга торган «Карчыга» исемле көлке журналының (1906 ел, № 2, ноябрь) «Митинг» дигән памфлетында Шакир Мөхәммәдев «Карчыга»ның беренче номерында: «Бәдигъ мәзиннең үткән ел Казанда югалган ата күркәсе бу ел Америкага барып чыкканы Нью-Йорктан хәбәр бирелгән иде. Шул күркә хәзер Казанга кайтып, үрдәк, каз, күркә, тавык кебек йорт кошлары арасында хөррият фикерен тарката башлаганын ишеттек... Күркәнең Америкада бирелгән исеме — Куыктыр» (Ш. Мөхәммәдев. Сайланма әсәрләр, 1958. – Б. 235-252), — дип башлап китеп, аллегориягә тартымлы итеп, 1905-1906 елларда татар иҗтимагый хәрәкәте эволюциясен, проблемаларын, кимчелекләрен көлкеле чагылдыра. Ш. Мөхәммәдевтән күреп, «Бәдигъ мәзин күркәсен» әдәбиятта уйнатуны Г. Тукай күтәреп ала. «Яшен» журналының 1909 елгы сентябрь санында басылган «Авыл җырларында» (икенче көлтә) бастырган:

Башымдагы чабатамның
сиксән сигез серкәсе.
Бу дөньяда шөһрәт алды
Бәдигъ мәзин күркәсе.

Бу юллар халык теленә кереп кала. Шул рәвешчә Бәдигъ мәзин исеме татар әдәбияты түренә үтеп, бер популяр әдәби персонажга әйләнә.

Бәдигъ мәзин исеме тагын бер фактта онытылмас-җуелмас рәвештә татар әдәбияте белән бәйләгән. Бәдигъ мәзин күңеле, холкы, омтылышлары, табигате, сәләте белән, әдәбиятка якын кеше булган. Ул дөнья хәлләреннән бихәбәр комсызлыктан күзе томаланган йомыкый да, ваемсыз кеше дә булмаган. Әдәбият кебек, талант, иҗат эшенә ул хөрмәт күрсәтә белгән.

Казандагы Каюм Насыйри музее шул Бәдигъ мәзин йортында урнашкан. Өлкән яшьтәге, караучысыз, йортсыз-җирсез әдипне, картлык көненде, Бәдигъ мәзин үз канаты астына сыендыра. К. Насыйри мәгърифәтчелек һәм иҗат эшчәнлеге белән шөгыльләнә алсын өчен, күп елларга, зур-зур бүлмәләрен, түләүсез, К. Насыйриның үз иркенә тапшыра. Уйлап карыйк әле: Казанда, кем кемгә мондый изгелек күрсәтә алган? Ә бит ул черегән бай булмаган. Күркә игъланы да шактый чикләнгән милек иясе бер кеше булганына үз ирониясе түгел микән әле? «Бәдигъ мәзин күркәсен» —

рухи, фикри чикләнгәнлек үрнәге санап, аңардан көлә беләбез. Ә аның К. Насыйрига күрсәткән олы җанлылыгы турында берәрсе телгә алдымы? Юктыр.

Университет китапханәсенең кулъязмалар бүлегендә борынгы язмаларны өйрәнеп утырганда каталогта Сибгат бине Бикмөхәммәд дигән кешенең 1893 елда язылган «Бәгъзе вакыйгате тарихи» (№ 594 т) дип күрсәтелгән бер кызыклы кулъязмасына юлыктым. Зур форматлы ун биттә гарәп телендә «Тәзкирәтел-фәкыйрь Сибгатулла бине Бикмөхәммәд, 31.01.1893» дигән дүрт бәет шигырь бар. Сибгат бине Бикмөхәммәд кулъязма авторы түгел икән. Дүрт юллы мәрсия аталмасында гына аның исеме шулай телгә алынган. Дәфтәрдә өч урында «Фәкыйрең Бәдигъ» (4 кгз.), «Бәдигъ бине Галим Хөсәенов», «Бәдигъ Хөсәенов» (7 кгз.) дигән имзалар кулъязманың һәм барлык язуларның Бәдигъ мәзиннеке икәнендә шик калдырмый. Димәк, Бәдигъ мәзиннең әтисе Галим исемле, фамилиясе Хөсәенов булган. К. Насыйри әтиләренә язган күп кенә хатларында Галим абзыйсының исәнлеген хәбәр итә. Аның әтисе дә Хөсәен улы «Галим абзый» — Габденнасыйр Хөсәен улының туганы (энесе), Каюм белән Бәдигъ икетуган балалары икән.

Исемен мәңгеләштергән ата күркәсе кебек үк, мәзин бабайның бу дәфтәр кисәге дә гүя шул максатка гына каратып эшләнгән. Ул өч бүлектән тора. 1). Әдәбият. Бу дәфтәрдә аның берничә прозаик һәм шигъри әсәр сызмалары бар. Сөйләм телебезгә якын әдәби төркидә язылган «Хәлифә Мәһди биллаһ һәм ком гарәбе» хикәясе. «Мужик бәетләре», остазы Кышкар Исмәгыйль ишан Үтәмешевкә зур мәрсия (1804-1884), «Шаһнамә»дән, «Фөзүли»дән 5-6 бәет тәрҗемәләре... Һәммәсендә чын шагыйрь кулы сизелә. Болар каләм сынау, өйрәнчек тәҗрибәләре дә була алмый, графоман әрсезлеге җимешләре дә түгел. Каюм бабай дәрәҗәсенә якын әдәби сәләткә ия булган кеше диясе килә. Шигырьләренең теле дә сөйләм теленә якын. Дөрес, менә бу эпиграммасындагыга охшаш чуар телле үрнәкләр дә бар:

Саләфләр кем, иреләр ба мөрәүвәт,
Диделәр: «Әл-карз икрази мәхәббәт»

Әмма кулъязманың төп өлешен (Б. 5-30), үзе үк «Бәгъзе вакыйгаи тарихия вә бәгъзе хараикъ гадәт эшләр» дип атаган 1886-1894 еллар «вакаигънамәсе» (үзенчәлекле елъязмасы) биләп тора. Сокландыргыч үлчәмлелек, ниндидер эчке кыйблалылык XIX гасырның икенче яртысында (Ш. Мәржани, Р. Фәхретдин, К. Насыйри) һәм XX йөзнең беренче елларында (Габдулла Мәгази) татарның яңа заман тарихына материаллар, сызмалар рәвешендә, укымышлыларның һәм кайбер күренекле кешеләрнең кыскача тәрҗемәи хәлләре китапларын («Мөстәфадел-әхбар»ның ике томы, «Асар»ның дүрт кисәге, «Некролог, яки кабер ташлары» (К. Насыйри), «Голәмаи кораэ» (Г. Мәгази), төзү эшләре җанлана. Бәдигъ мәзин, «Вакаигънамә» язу традицияләре нигезендә, бу юнәлештәге эшчәнлекне яңа бер тармакта киңәйтеп җибәрү эшенә алына һәм безгә мәгълүм дәфтәрендә бу юнәлешнең ниндидер нәтиҗә күрсәткән бердәнбер билгеле вәкиле булып кала. Шул яңалыгы һәм уникальлеге аны югарыда саналган күренекле галимнәребез белән бер рәткә куя. Шул беренчелеге һәм бердәнберлеге, күрәсең, аның бу язмасын тематик яктан да киң эчке тармакларга китереп чыгарган. Үзенең кешелек миссиясе Ш. Мәржаниләр рәтендә булуын автор үзе дә сизә, таный кебек. Ш. Мәржани абруе татарның һәр китап әһеленә остазлык дәрәҗәсенә ирешкән шартларда ике шәхес, К. Насыйри һәм Бәдигъ мәзин генә, безнең белүебезчә, шәкертлек сызыгында түгел, тиңдәшләрчә, оппонентлык чикләрендә тора алганнар. Ш. Мәржанинең «Мөстәфад»ында Хисаметдин Мөслими «Тәварих Болгария»сенә тәнкыйтенә К. Насыйри җитди һәм кыю анализ белән чыга. «Бәгъзе вакыйгаи тарихия» язмасының башында ук (Мөхәммәдьяр Солтанов мөфти итеп сайлану хәбәреннән соң), 1886 елда Шиһаб хәзрәтнең 18 яшьлек кызга өйләнүе турында язма урнаштыра. Күпләр, башкалар да бу фактны хәзрәтнең абруена күләгә төшерә торган хәл дигән карашта булганнар, күрәсең, безнең белүебезчә, бу факт башка бер урында да телгә алынмый. Бәдигъ мәзин язган: (Шиһабетдин Мәржани) Буа Габденнасыйр кызын унсигез яшендә гакыд кылды. Вә зөфаф — 75 яшендә (чынлыкта 68 яшь). Вә җәмәгатендә күп җәнҗаллары һәм булды (соңыннан өстәгән күрәсең). Бәгъдә, ике сәнә ярымнан соң, Шиһаб дамелла вафат тапты. Берникадәр вакыттан соң яшь остабикә Сафа хаҗига Галикәевкә барды. Бер айдан Сафа хаҗи вафат. Үз урынында, «Вафате голәма» бүлегендә, өченче кеше итеп 1886 елда «30.03.1886 Буави дамелла Габденнасыйр

Мөхәммәдәмин углы 90 яшендә вафат» булуы хәбәр ителә. «Буави дамелла» булса да, Габденнасыйр хәзрәт соң гомерен Казанда яшәгән булуы мөмкин. «Шиһаб дамелла» 70 яшь бусагасында, яшь хатын дәртендә, Буага барып, кыз яучылап-туйлап йөри алыр микән? «Вафате әһле [алтынчы] мәхәллә» бүлегендә Сафа хаҗи бине Галикәйнең 68 яшендә 1890 елда вафат булганын язган.

Ш. Мәрҗани исеменә кагылышлы тагын бер хәбәр 29.01.1890 датасы белән язылган. Ш. Мәрҗани вафатыннан соң, мәдрәсәсендә шәкертләр тавышлануы булып ала, карт остазларын юксынган яшьҗилкенчәк [шәкертләр], 25 ел мәдрәсәдә укытучы булып эшләгән Ш. Мәрҗанинең кияве, Сафиулла тирәсенә сыеналар. Әтисе вафатыннан соң, улы Мөхәммәд дамелла була. Ике ай ул дәрескә чыкмый тора. Барча шәкертләрне, барлык фәннәрне Сафиулла мөгаллим укытып тора. Мөхәммәд мәхдүм дәрескә керә башлагач, шәкертләр белән араларында конфликт чыга. Бер шәкерт бер сүзне аңлатуны сорый. «Сезне бу эшкә Сафиулла котырткан», — ди, мәхдүм җавап бирми. Шәкертләр: «Без сиңа утырмыйбыз: син — надан, — гомеребез заигъ үтә», — дип дәресен ташлап чыгып китәләр. Мәхдүм мәхәлләгә чыгып зарлана. Мәхәллә олылары кереп: «Яхшы торыгыз!» — дип үгетләгәннәр. Шәкертләр көлгәннәр, мәсхәрә кылганнар, барабан какканнар. Тегеләр чыгып, полицияга зарланганнар. Полиция губерна идарәсенә хәбәр итә һәм шәкертләрне мәдрәсәдән куа. Мәхәллә халкы ике лагерьга бүленә. Бер як, Сафиуллага приговор җыя. Моңа каршы, мәхдүмгә кызгану йөзеннән приговор җыялар. Күрәсең, губернатор аралашып [Сафиуллага] яңа частьта шәкертләр укытырга фатир алып, шунда чыгаралар. «Барабара ни була, янә язармын. Бәдигъ. 30.01.1890», — дип куйган. «Җәй башында [Сафиулланы] Хан кальгасына (күрәсең, Бүкәй урдасы үзәге күз алдында тотыла) мәдрәсә имамы итеп, 40 шәкерте белән алмакчы булалар. Ике тараф та риза була. Китәм дип торганда мәхдүм тарафы: ул котыртырга бара. Казакларга Казанда шундый-шундый эшләр эшләде дип судка күрсәтеп, ахыр, аларны ханга булмаска эшләделәр [карар чыгарттылар]. Октябрь башында [Сафиулла] шәкертләренә әйтте: кайсы мәдрәсәгә барсагыз да рөхсәт: мин укыта алмыймын, диде. Шәкертләр биш мәдрәсәгә таралдылар». Ш. Мәрҗани хәзрәтләре мәдрәсәсенең бу фаҗигасы да, Бәдигъ мәзиннең шул язмасыннан башка, беркайда да чагылганы юк кебек.

Г. Баруди турында теркәп калдырган ике хәбәренең берсе Ш. Мәрҗани исеменә кагылып китә. Үзе вафатыннан соң, аның ахунлык дәрәҗәсен Казанның бер имамына бирергә тиеш булалар. Шәһәрдә абруе зур әтисе бу дәрәҗәне улы Галимҗанга аласы иткән. Әмма шул ук мәхәлләдә Галимҗан хәзрәттән 15 еллар элек имамлык итә башлаган өлкән яшьтәге Йосыф хәзрәт бар. Бер ахунлык урынын имамнарның икесенә дә бирүне юллап йөргәндә, тагын да зуррак булдыклылык күрсәтеп, Хуҗаәхмәт мулла Уфага барып, үзе ахун булып кайта. Әмма бу дөнья дигәнең шундый «үткен» Хаҗиәхмәт хәзрәт булсаң да, сөртендерә. 1892 елда аның указы алынуы, хибескә (төрмәгә) эләгүе турында язма бар. Сәбәбе хакында бер сүздә юк. 1894 елда шул урынга ике ахун Г. Баруди һәм Йосыф хәзрәт билгеләнә.

«[...] 5.03.1891 сәнә Тәтеш өязе Салтыкның Гәрәй исемле талибе гыйлем 35 яшьтә мөртәт булды [чукынды] 1 200 тәңкә вазыйфа [эш хакы] илән [духовная] академиягә гарәпчә укытырга куйдылар.

25.01.1892 елда губернаторны бер урыс атты өч мәртәбә. Берсе тиде. [...]»

Фаҗигале хәлләре дә безнең заманга аваздаш. Техника заманы башлану белән, ул күп йөзләп кешеләрне һәлакәт упкынына юлыктыра. «10.08.1888. Әстерхан илә Саратов арасында «Самолет» пароходы янды. 300 адәм вафат, 50 кеше — йөзеп чыкканнар. Пароход, көллән [тулысынча] янган. Мәкәрйәгә баручылар күп икән, 15 мөселман да бар икән. Янә 1886 ел август ахырында җөк пароходы казаны ярылды, 50 адәм вафат».

Хәер, халыкның каралыгыннан туган һәлакәтләр колачы да техникадан калышмый. «4.01.1892 елда, Одеста, хач [тәре] манганда, боз күпер җимерелеп, 1000 урыс диңгезгә төшеп [батып] вафат. Табигый афәтләр..., 1891 сәнә июнь, июль, август бик эссе булды. Рәсәйдә ашлык булмады, каткан җир булды. Солы [поты] — бер сум ун тиен, арыш — бер сум кырык тиен... Ничә мең адәм ачка вафат булды. Ничә-ничә мәмләкәттән акча җыеп җибәрделәр. Казанда, бер мең мөселман фәкыйре[н], 6-7 йөз сабыйлары[н] ашаттылар яңа арышкача».

«1892, гыйнвар, февраль, март, апрель, майда Казанда тиф марзы куәтле булып, мөселманнардан 1500 кеше вафат».

«1892 сәнәдә июнь, июльдә ваба булды. Кызылбаш (Иран) эчендә, Шәмәхадә, Сәмәрканд, Ташкент, Әүлия Атада һәм куәтлерәге — Әстерханда. Казанда һәм бераз булды, берәр йөз мөселман [вафат]. 1893тә дә бераз булды».

«1894 сәнә. Авыл-авыл һиҗрәт кылалар, Истанбулга, Мәккәгә, Мәдинәгә, Россиядә хәвеф бар, дип. Бастырмаган китаплар укылмаска. Китапларны цензурсыз бастырмый [...]».

«1895 сәнә. Су бик куәтле килде. Күп йортлар уалды. Май 11ендә кими башлады».

Язманың бу бүлегендә авторның биографиясенә кагылышлы материаллар да бар. Аларның кайберләре «Хатирә дәфтәре» сызмаларын хәтерләтәләр. «16.07.1888. Йосыф хәзрәт мәхдүме Мөхәммәдвәли Бохараи шәрифкә китте. Фәкыйрәнез Бәдигъ Спасский затонга кадәр озатты. Аннан Болгар шәһәренә йөреп, якшәмбе көн кайттык». «1890 сәнә, июльдә кымызга бардым, башкортка». «11-15. 05. 1891. Шырдан, Кармыш кариялерен йөреп кайттым».

Төрле елларда ел фасылларындагы һава хәлләре, явым-төшемнәр, боз китү, су ташу, чана юлы төшү турындагы язмалары, шул төркем материалларга якын тора. Автор биографиясенә кагылышлы тагын кызыклы бер төркем материаллар бар. Болар — «Общественный банк»ка акча салуы һәм Рәфикъ исемле улын Сатыш мәктәбендә укыту белән бәйле материаллар. Алар ул чор урта кул татар гаилә тормышының бүген инде онытыла барган күп кенә конкерт якларына яктылык кертәләр...

«21.11.1893 сәнә. (13 яшьлек) Рәфикъны Сатыш мәдрәсәсенә укырга илтеп кайттым, 17 сум расходы булды», — дип башлап, кайчан күпме акча җибәрүләрен, кайтканында, нинди максатларга күпме акча(сы) таратылуын шулай ук, бухгалтерия китабындагыдай, берәмтекләп язып күрсәтә. Шулай, банкта җыелган акчалар, малайның уку чыгымнарына тотыла. Милек мөнәсәбәтләре, шәкерт бюджеты конкрет күз алдына бастырылалар.

Язманың икенче бүлеген автор «Вафате голәма рәхмәтуллаһи әҗмәгыйн» дип атый. Бу бүлек турында сүз чыккач искәртеп китик: 1885нче елда Ш. Мәржанинең «Мөстәфадел-әхбар»ның беренче томы басылып чыга. Бу хезмәт кулъязма хәлендә үк укымышлылар күзенә элэккән булырга охшый. «Мөстәфад»ның басылып чыгуы — ул көнге татар мәдәнияте тормышында, масштабы белән булмаса, мәгънәви функция эчтәлеге буенча (XVIII йөз француз энциклопедиясе кебегрәк), шуннан соңгы яшәешнең мәгънәви барышында тәэсир күрсәтә торган факторга һәм күренешкә әйләнә. Бәдигъ мәзин язмасының беренче бүлеге турыдан-туры Ш. Мәржани «Мөстәфад»ыннан үсеп чыккан. Менә бу «Вафате голәма...» бүлеге дә «Мөстәфад»ның ике томы белән принципиаль бәйләнештә торганы аңлашыла. Автор күренекле укымышлыларның исемнәрен, дөньядан үтү елларын тарихыбызда саклауны, мәңгеләштерүне кайнар яклый. Бу эшне ниндидер биографияләрен булдыру омтылышы рәвешендә генә түгел, үз язмасы кебек, төрле вак жанрларда да, кәгазьгә теркәү рәвешендә генә булса да, яшәүчән һәм тотрыклы яңа күренешкә әйләндерү чарасын ишәйтүне кайгырта. Бу бүлектә дә Бәдигъ мәзин Ш. Мәржанигә турыдан-туры ияргү, кушылу юлыннан бармый. Мәсьәләгә иҗади якынлашып, замандашы башлаган үтә мөһим эшне, яңалыкны киңәйтү, ишәйтү юлын тота.

Язмада алтмышлап кешенең вафаты хәбәр ителә. Күпчелегенә кыскача, әхлакый бәя бирелә. Мәсәлән, менә ике коданың вафаты хәбәре:

«93нче сәнә Хөсәен хәзрәт (Әмирхан), Яңа Бистә, гыйнвар 10ында вафат».

«93нче сәнә, май 28ендә Чистай ишан дамелла Закир бине Габделвәһһаб 85 яшьтә вафат. 50 мең сумасы, 14 баласы калды. Тәкъва, галим адәм иде. Хода шәфәгатен насыйп итсен иде».

Географик колачы бик киң: язмада Ханкирмән, Тройски, Петропавел, Бохарада вафат булган кайбер татар укымышлылары, хаҗдан кайтышлый, Мисырда, Истанбулда вафат иткән муллалар турында хәбәрләр дә бар.

Бу икенче бүлеккә «Вафате әһле мәхәллә» дигән, үз хезмәте буенча, алтынчы мәхәллә халкыннан, 1886-1896нчы елларда мәрхүм булганнар исемлеген дә кушып карарга була. Автор шундый тәжрибә дә ясап карый. Бу зур исемлекне без югарыдагы хисапка кертмәдек, бу аның гадәти, көндәлек эш кәгазьләре булганмы, яки ул гади кешеләрне дә зур тарих бизмәненә якынайту омтылышы күрсәткәнме, безгә юрарга гына кала.

Бәдигъ мәзиннең сакланып калган язмаларына ясаган күзәтүебездән шул нәрсә аңлашыла: автор — актив табигатьле, иҗади характерлы күп яклы таланталы җан

иясе булган, уй һәм омтылышлары буенча заманының иң алдынгы фикер, иҗтиһад һәм иҗат ияләре янәшәсендә торган. Язмаларыннан, аның талантлы каләм иясе булганы аңлашыла. Бу дәфтәрдән башка да, әлбәттә, язмалары булгандыр. Эзләнүләр, биографиясен өйрәнү, киләчәктә, бу мәсьәләләргә күп ачыклыклар кертер дип ышанасы килә. Бу кулъязмасы нигезендә инде аның иҗтимагый фикер тарихында, шигырьләрен искә алганда, әдәбиятыбыз тарихында игътибарга алырлык урыны булганы бәхәс уятмый. Укучылар игътибарына аның кайбер шигырьләрен тәкъдим итәбез.

Гөл булырмы, әй күңел, галәмдә, чөнки, харсыз?!
Гаепсез яр истәюб калма җиһанда ярсыз!
Кәнҗ улырмы бу җиһанда, чөнки, ул марсыз?!
Шәхес улырмы, чикмәс михнәтләр дилдарсыз?!
Әй җәрири, нәхс талигътан шикайәт әйләмә,
Гомер улырмы кем, кичәр дөньяда аһ-зарсыз!

Бәет «Шаһнамә»

Очырсын, — кош кеби оч сәмая
Кидәрсен, соң әүҗи әүҗи тәхб-ш-ширая
Нәдер дөнья, аңа сән шад уласын
Күңел биреп, аны мәхрәм кыласын?!
Аны мәхрәм идәннәр калды мәхрүм,
Аның шөкрен идәннәр калды мәзмүм.
Җиһанның бакма татлы нигъмәтенә,
Инанма ул ялганчы дәүләтенә.

Мужик бәетләре

Җыртылган чабатадыр аягында,
Алын-салын, күлмәкләре һәм өстендә.
Кып-кызыл кан, — бер нәрсә юк һәм башында, —
Ачык башын эссе кояш кыздырыр имди.
Ул, бичара, ничә еллар эшләп йөри:
Озын көннәр сука берлән сабан сөреп
Һәм, ындырда, ашлык суырып, көшел сөзеп,
Бер эш бетсә, икенчесен башлар имди.
Гомере буе ятадыр хезмәт итеп,
Сука берлә җир тырмый, иртә китеп,
Сукасының берсе төзек, берсе китек,
Тимере үтсә, сука башы бозык имди.
Киң учының төпләренә сөял үскән,
Кул тирәли суелу белән ярылып төшкән. —
«Бәхетсезлек төшмәс бугай безнең өстән.
Мужик булган моңсыз булмас», — диер имди.
Ничә сука ватадыр ул гомерендә
Ничә көрәк сындыра ул җылында, —
Һич нәрсә түзми аңа, эшләгәндә,
Әле дә, мескен тырыш мужик түзә имди.
Мискин мужик, гомере буе эш эшлидер.
Өстеннән иске кием һич төшмидер.
Күп байларның моңа бер дә эч пошмыйдыр,
Кайда күрсә, анда тотып сүгә имди.

Мәсгуд Гайнетдин,
филология фәннәре докторы

РЕЗЮМЕ
Статья доктора филологических наук М. Гайнетдинова освещает биографию и творческое наследие Б. Хусаинова, являвшегося родственником знаменитого татарского ученого К. Насыри.